СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
24 сентябрь 2018 ел

Карар
№ 2-35

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017елның17сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 18 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге №2-33карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмә (17.09.2018 № 5-34 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер

авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1**.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
- Җөри торак пунктында Заречный урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү:
- Түбән Шүләңгер авылында су башнясын алыштыру;
- Урта Шүләңгер авылында чишмәне төзекләндерү;
- Березовая Поляна поселогындагы чишмәне төзекләндерү;

3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- Комаровка авылы зиратын койма белән әйләндереп алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. . Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Е.М.Михайлова/